РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР
СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2026 елның 04 июне № 23

Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау турында» 2025 елның 12 декабрендәге 19 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау турында» 2025 елның 12 декабрендәге 19 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарны түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт белән тулыландырырга:

«1.1. Әгәр әлеге карарны кабул итү көненә кадәр алты ай эчендә вәкаләтле орган тарафыннан социаль объектлар һәм күпфатирлы йортлар төзүне күздә тота торган территорияне планлаштыру проектын эшләү буенча бурыч расланган булса, ә 2025 елның 12 декабренә планлаштыру проекты билгеләнгән тәртиптә расланмаган булса, проект оешмалары җиңел автомобильләрне парковкалау өчен машина урыннары санын исәпләгәндә (даими һәм вакытлыча саклау өчен), күрсәтелгән объектларга карата Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлауның әлеге карар кабул ителгән көнгә кадәр гамәлдә булган җирле нормативларын кулланырга хокуклы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр инфраструктурасы үсеше һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры — Р.И. Беляев

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ГОРОД НИЖНЕКАМСК РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН